| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ**<br>**20.09.2017** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 231** |

Зеленодольск муниципаль районында проект идарәсен гамәлгә кертү турында

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары С.В. Кадыйрованың Зеленодольск муниципаль районында проект идарәсен гамәлгә кертү турындагы мәгълүматны тыңлап фикер алышканнан соң, Зеленодольск муниципаль районы Советының 2016 елның 09 сентябрендәге 124 номерлы карары белән, (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2017 елның 12 июлендәге 203 номерлы карарына кертелгән үзгәрешләр белән) расланган, 2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәр план чорына Зеленодольск муниципаль районын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен гамәлгә ашыру максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Зеленодольск муниципаль районында проект идарәсен гамәлгә кертү турындагы мәгълүматны исәпкә алырга.
2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына:

2.1. 2017 елның 1 октябренә кадәр түбәндәгеләрне расларга:

- Зеленодольск муниципаль районында проект идарәсен гамәлгә кертү турында нигезләмәне;
- Зеленодольск муниципаль районының Проект комитеты турында нигезләмәне;
- Зеленодольск муниципаль районының Проект офисы турында нигезләмәне;
- Проект комитетның структурасын.

2.2. 2017 елның 1 ноябренә кадәр:

- Зеленодольск муниципаль районының «Зеленый Дол» инвестиция үзәге» автоном учреждениесе (Проект офисы) структурасына үзгәрешләр кертергә;
- проект идарәсенең инструментларын һәм ысулларын апробацияләү өчен пилот проектларын эшләтеп җибәрүне расларга;
- Проект комитеты һәм Проект офисы җитәкчеләре, проект идарәсенең сынау проектларында катнашучылар өчен укулар үткәрергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Советының социаль – икътисадый үсеш, бюджет – финанс мәсьәләләре, муниципаль милек һәм эшмәкәрлекне үстерү буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Зеленодольск**
**муниципаль районы Башлыгы,**
**Совет рәисе** **А.В. Тыгин**